| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕТИГАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ЗУР ТИГӘНӘЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2023 с. Большие Тиганы № 60

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципал районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 3 ноябрендәге 40 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 статьясы нигезендә

**Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы карар итте:**

1.«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 3 ноябрендәге 40 номерлы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3 статьяның 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен)» сүзләре белән алыштырырга;

- 18 статьяның 1 пунктындагы б пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен)» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталындагы җирлек сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Зур Тигәнәле авыл**
**җирлеге Башлыгы,**
**Совет Рәисе** **М.А.Гатин**